ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 28 гыйнвары**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 126**

«2016 - 2018 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2015 елның 10 декабрендәге 2728 номерлы Татарстан Республикасы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырылган төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2016 - 2018 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2015 елның 10 декабрендәге 2728 номерлы Татарстан Республикасы Башкарма комитеты карары белән расланган, 2016 - 2018 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына (алга таба - кыска сроклы план), кыска сроклы планны яңа редакциядә бәян итеп, ,әлеге карарның № 1, № 2/1, №2/2, №2/3, №3/1, №3/2, №3/3, №4/1, №4/2, №4/3, кушымталарында каралганча үзгәрешләр кертергә.

2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин